РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
ТИМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТИМБАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 сентябрь 2018 ел № 54-2

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Тимбай авыл җирлегендә
гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау
регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртипләре турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ нормерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлеге Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Буа районы Тимбай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» 2014 елның 22 октябрендәге 1-60 номерлы карары белән расланган (2018 елның 5 мартындагы 43-1 номерлы Карары редакциясендә), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Тимбай авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Регламент текстын:

түбәндәге редакциядә бәян итеп, VI.I бүлек өстәргә:

**«VI.I. Гражданнарның коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләрен карау.**

6.1.1. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, гражданнар коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләрен органнарга юнәлдерергә хокуклы.

6.1.2. Гражданнарның коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләре үз эченә коррупция һәм янап алу, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләү, хезмәт тәртибенә таләпләрне бозу, шулай ук хезмәт

урынынnан законсыз файдалану билгеләре булган башка гамәлләр турында мәгълүматларны ала.

6.1.3. Кабул ителгән мөрәҗәгатьтә әзерләнүче, кылына торган яки кылынган законсыз гамәл, шулай ук аны әзерләүче, кыла торган яки кылган зат турында мәгълүмат булса, андый мөрәҗәгать хокук саклау органнарына аларның компетенцияләре нигезендә юнәлдерелә.

6.1.4. Гражданнарның коррупция юнәлешендәге фактлар буенча мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазифаи затлар хезмәт мәгълүматы һәм конфиденциаль холыктагы хәбәрләрнең сакланышы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә персональ җаваплылык тота.

6.1.5. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе органнарның норматив хокукый актлары тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге Карар рәсми рәвештә бастырып чыгару көненнән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районының
Тимбай авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вәлиев